**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар**

**2021 елның 10 ноябре** **№38**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Тәмте авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 87 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Тәмте авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 87 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Тәмте авыл җирлеге Советы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Тәмте авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кадастр номеры 16:22:090108:191 территориаль зонаны СХ-1 дән Ж-1 гә үзгәртергә.

2.Әлеге карарны Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесенә Тәмте авыл җирлегенең генераль планы проектын эшләгәндә исәпкә алу өчен җибәрергә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге башлыгы И.А.Зиновьевка йөкләргә.

Тәмте авыл җирлеге башлыгы И. А. Зиновьев